# МАТЕМАТИКА

# Тема

Тапкырлау таблицасын ныгыту.

Мәсьәләләр чишу.

# Максат:

1.Тапкырлау таблицасы турындагы белемнәрне ныгыту.

2. Кыскача шартын төзеп, мәсьәләләр чишә белүне камилләштерү.

3. Логик һәм иҗади фикерләү үсешенә ярдәм итү, телдән исәпләү күнекмәләрен ныгыту.

Таблицадан тапкырчыгышларны түгәрәкләп чыгарга

1, 2, 3, 4, 5, 6, 7, 8, 9, 10,
11, 12, 13, 14, 15, 16, 17, 18, 19, 20,
21, 22, 23, 24, 25, 26, 27, 28, 29, 30,
31, 32, 33, 34, 35, 36, 37, 38, 39, 40,
41, 42, 43, 44, 45, 46, 47, 48, 49, 50,
51, 52, 53, 54, 55, 56, 57, 58, 59, 60,
61, 62, 63, 64, 65, 66, 67, 68, 69, 70,
71, 72, 73, 74, 75, 76, 77, 78, 79, 80,
81, 82, 83, 84, 85, 86, 87, 88, 89, 90,
91, 92, 93, 94, 95, 96, 97, 98, 99, 100.

# Җавапларны тикшерү

1, 2, 3, 4, 5, 6, 7, 8, 9, 10,
11, 12, 13, 14, 15, 16, 17, 18, 19, 20,
21, 22, 23, 24, 25, 26, 27, 28, 29, 30,
31, 32, 33, 34, 35, 36, 37, 38, 39, 40,
41, 42, 43, 44, 45, 46, 47, 48, 49, 50,
51, 52, 53, 54, 55, 56, 57, 58, 59, 60,
61, 62, 63, 64, 65, 66, 67, 68, 69, 70,
71, 72, 73, 74, 75, 76, 77, 78, 79, 80,
81, 82, 83, 84, 85, 86, 87, 88, 89, 90,
91, 92, 93, 94, 95, 96, 97, 98, 99, 100.

# Сораулар

- 1.Турыпочмаклыкның периметрын, мәйданын ничек табалар?
- 2. Квадратның периметрын, мәйданын ничек табалар?
- 3. Җөп, так саннар дип нинди саннарны атыйлар?

**3) Дәреслекнең 62 нче битендәге №4**

- 4 ,5 ,7, 8, 9 саннары бирелгән.
- А) һәр җөп санны 2 тапкырга кимет,
- Б) һәр так санны 9 тапкырга арттыр.

# Күнегүләр эшләү

**Саннарны язарга.**

а) 12 дән 3 тапкыр ким.
б) 20 дән 5 кә зуррак
в) 8 дән 4 тапкыр зуррак

**Аңлатмаларны языгыз һәм чишегез.**

а) 24 санын 4 һәм 2 саннарының тапкырчыгышына бүл һәм исәплә.
б) 81 һәм 9 саннарының өлешен 5 кә тапкырла.
в) 53 һәм 11 саннарының суммасын 8 гә бүл.

# Күнегүләрне тикшерү

- **Саннарны язарга.**
- а) 12 дән 3 тапкыр ким. | 4
- б) 20 дән 5 кә зуррак | 25
- в) 8 дән 4 тапкыр зуррак | 32

- **Аңлатмаларны языгыз һәм чишегез.**
- а) 24 санын 4 һәм 2 саннарының тапкырчыгышына бүл һәм исәплә. 24: (4*2)= 24:8=3
- б) 81 һәм 9 саннарының өлешен 5 кә тапкырла.

  (81 : 9) * 5 = 9 * 5 = 45
- в) 53 һәм 11 саннарының суммасын 8 гә бүл.


  ( 53 + 11) : 8 = 64 : 8 = 8

# Мәсьәләләр чишу

# III. Текстлы мәсьәләләр чишү

Дәреслекнең 63 нче битен ачып №1 мәсьәләнең эчтәлеге,сызымы белен дә танышыгыз.

- 24 троллейбус ничә көндә төзәтелгән?
- 1 нче көнне ничә троллейбус төзәткәннәр?
- 2 нче көнне ничә троллейбус төзәткәннәр?
- 3нче көнне ничә троллейбус төзәткәннәр?



# Мәсьәләнең кыскача язылышы

**I - 8 тр.**

**II - 10 тр.**

**III - ?**

24 тр.

# Чишү

**I ысул**

8+10=18 (тр.) ике көндә төзәтелгән

24-18=6 (тр.) өченче көнне төзәткәннәр

**II ысул**

24-(8+10)= 24-18=6 (тр.) өченче көнне төзәткәннәр


Җавап: Өченче көнне 6 троллейбус төзәткәннәр.

# ЯЛ ВАКЫТЫ

Тәрәзә каршына
Килгән бер чыпчык.
Миңа эндәшә:
-Чык әле, чык!
Алдалый ул, беләм
Гел шулай итә,
Йөгереп чыксам
Оча да китә.

2) Дәреслектәге 4нче мәсьәләнең шартын укып танышыгыз һәм сызымын сызыгыз.

- Балалар ничә кызыл божра ясаганнар?
- 10 кызыл божра сызыгыз.
- Ничә сары божра ясаганнар?
- 6 сары божра ясагыз.
- Чылбырны ничек җыйганнар?
- 8 әр божра куеп чылбыр төзегез. Ничә чылбыр килеп чыкты?



Мәсьәләнең чишелешен,төзегез дәфтәрегездә эшләп куегыз.

# Чишү

**1) 10 + 6= 16(божра) барлыгы**
**2) 16 : 8 = 2 (чылбыр)**

Җавап: 2 чылбыр ясап була.

# ТЕСТ

1.Китап 56 битле. Азат көн саен 8 битен укый. Ул бу китапны ничә көндә укып бетерер?

а) 7көндә б) 9көндә в) 8 көндә

2. Беренче китап 9 битле. Бу икенче китапка караганда 3 тапкыр кимрәк. Икенче китап ничә битле?

а) 3 битле б) 6 битле в) 27 битле

3. Бер китап 40 битле, ә икенчесе 5 тапкырга кимрәк.Ике китап ничә битле?

а) 45 битле б) 48 битле в) 75 битле

4.Беренче китап 30 битле, ә икенчесе 10 битле. Беренче китапның битләре икенчесенә караганда ничә тапкыр күбрәк?

а) 10 тапкыр б) 3 тапкыр в) 5 тапкыр

5. Турыпочмаклык формасындагы китап тышының буе 12 см, иңе 8 см. Бу турыпочмаклыкның периметрын табыгыз.

а) 40 см б) 20 см в) 60 см

# тестның җаваплары

1 - а

2 - в

3 - в

4 - б

5 - а

**Мөстәкыйль эш.**

А)Әни 32 пәрәмәч пешерде. Шуларның 13 ит белән, 9 творог белән, калганнары алма белән. Әни ничә алма пәрәмәче пешергән?

Б) Класста 7 кыз һәм 9 малай. Аларны берләштереп ике командага бүлделәр. Һәр командада ничә бала булыр?

# Мөстәкыйль эшнең җавапларын тикше

А)Әни 32 пәрәмәч пешерде. Шуларның 13 ит белән, 9 творог белән, калганнары алма белән. Әни ничә алма пәрәмәче пешергән?
Чишү: 32 -(13+9)=32-22= 10 алма пәрәмәче.
Җавап: әни 10 алма пәрәмәче пешергән.

Б) Класста 7 кыз һәм 9 малай. Аларны берләштереп ике командага бүлделәр. Һәр командада ничә бала булыр?
Чишү: (7+9) :2=16:2=8 (бала) 1 командада
Җавап:Һәр командада 8 бала .

# Өй эше

Дәреслектәге 63нче биттәге мисал өчне эшләргә.